КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 февраль г.Казань № 145

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 март, 173 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 789 нчы; 2020 ел, 10 март, 181 нче; 2020 ел, 14 май, 389 нчы; 2020 ел, 30 декабрь, 1247 нче; 2021 ел, 16 июль, 580 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибенең 5 пунктындагы бишенче абзацында татар текстында «эшкә кабул итү турында боерык күчермәсе» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы гаилә фермер династиясе» республика конкурсында җиңүчеләргә – крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына премияләр түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибенең 4.3.4 пунктында «документлар» сүзеннән соң «(аларның күчермәләре)» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин